# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге составына керүче Мостафин авылында 2024 елда үзара салым кертү турында

30 март 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге башлыгының 20.03.2024 «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында" 2023 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, "Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча "Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында гражданнар җыенын 2024 елда билгеләү турында» Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1.«Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлегенең Мостафин торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 2 номерлы карарларына түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

«1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Мостафин торак пунктында урам яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау;

2. Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Мостафин торак пунктында юлларны кардан чистарту (килешү буенча йортуче хезмәтләренә түләү);

3. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Мостафин торак пунктында һәйкәл төзү һәм янәшәдәге территорияләрне төзекләндерү – материаллар сатып алу, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);

4. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Мостафин торак пункт территориясендә үлән чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү); триммер очен, запас частьләр, чыгым материаллары, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторны тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу, килешү буенча йөртүче хезмәтләре өчен түләү)?».

2. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Петровский Завод авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы

сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Петровский Завод авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Нуртдинов